БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_28___» __01_____ 20_20_ г. № __45___

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары исемлеге турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2015 елның 30 июнендәге 295 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 7 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары исемлеге турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2015 елның 30 июнендәге 295 номерлы карарына (2018 елның 12 гыйнварындагы 15 номерлы, 2018 елның 21 маендагы 150 номерлы, 2019 елның 28 мартындагы 144 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктында, карарга 1 нче кушымтаның исемендә «2.14» саннарыннан соң «2.16 статьясы» сүзләрен өстәргә.

1.2. 1 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 10 пункт белән тулыландырырга:

«10. 2.16 статьяда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының әйдәп баручы белгече;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча секторының баш белгече;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының әйдәп баручы белгече».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов